ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.09.2025 г.Казань № 204-141/тп-2025

2026 елга «Шифалы Су - Ижминводы» шифаханәсе дәвалау-профилактика хосусый учреждениесенең үзәкләштерелгән су агызу системасына тоташтыруга (технологик ялгауга) тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «Капиталь төзелеш объектларын кайнар су белән тәэмин итүнең, салкын су белән тәэмин итүнең һәм (яисә) су агызуның үзәкләштерелгән системаларына тоташтыру (технологик тоташтыру) кагыйдәләрен раслау турында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым актларының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең аерым актлары нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2021 елның 30 ноябрендәге 2130 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мөрәҗәгать итүчеләрнең су белән тәэмин итүнең һәм (яки) ташландык суларны агызуның үзәкләштерелгән системаларына тоташтырган (технологик ялгаган) өчен индивидуаль тәртиптә түләү билгеләнә торган объектларының тоташтырыла (ялгана) торган йөкләнеш зурлыгын билгеләү турында» 2017 елның 22 апрелендәге 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 24.09.2025 ел, № 17-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә «Шифалы Су - Ижминводы» шифаханәсе дәвалау-профилактика хосусый учреждениесенең (алга таба – «Шифалы Су - Ижминводы» шифаханәләре профсоюзлары учреждениесе) үзәкләштерелгән су агызу системасына тоташтыруга (технологик ялгауга) тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2026 елның 1 гыйнварыннан 2026 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Су агызуны гамәлгә ашыручы «Шифалы Су - Ижминводы» шифаханәләре профсоюзлары учреждениесенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын башкаручы А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
24.09.2025 № 204-141/тп-2025
карарына кушымта

«Шифалы Су - Ижминводы» шифаханәләре профсоюзлары учреждениесенең үзәкләштерелгән су агызу системасына тоташтыруга (технологик ялгауга) тарифлар

| Т/с | Күрсәткеч | Үлчәү берәмлеге | Тоташтыруга тарифлар (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| 1. | Тоташтырыла торган йөкләнешкә тарифның база ставкасы | мең сум/тәүлегенә куб.метр | 1,7455* |
| 2. | Челтәрләр озынлыгына тарифның база ставкасы | мең сум/км | 22 861,78 |
| 3. | Челтәрләр диаметрына карап, тарифны дифференциацияләү коэффициенты: | | |
| 3.1. | диаметры 40 мм һәм азрак | - | 0,50 |
| 3.2. | диаметры 40 мм югары, 70 мм кадәр | - | 0,50 |
| 3.3. | диаметры 70 мм югары, 100 мм кадәр | - | 0,58 |
| 3.4. | диаметры 100 мм югары, 150 мм кадәр | - | 0,58 |
| 3.5. | диаметры 150 мм югары, 200 мм кадәр | - | 0,50 |
| 3.6. | диаметры 200 мм югары, 250 мм кадәр | - | 0,58 |

Искәрмә: * «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль законның 18 статьясының 13 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге